ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НОРМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
БАЛТАСИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ
НОРМА
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«15» июль 2022 ел № 6

**Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибен һәм вакытларын раслау турында**

2021 елның 16 сентябрендәге № 1569 номерлы «Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнарына (дәүләт органнарына), территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары белән идарә итү органнарына, җирле үзидарә органнарына, җирле администрация органнарына бюджет керемнәренең баш администраторы вәкаләтләрен беркетүгә һәм Россия Федерациясе субъекты бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслауга, территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты, җирле бюджетка карата гомуми таләпләрне раслау турында»гы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары нигезендә, 2021 елның 30 декабрендәге 1345 номерлы «Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибен һәм вакытларын раслау турында»гы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына таянып, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге башкарма комитеты **карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибен һәм вакытларын расларга.
2. Әлеге карарның гамәлдә булуы 2022 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.
3. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» интернет – ресурсында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Норма авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы Р.Р. Гыйлаҗетдинова

Татарстан Республикасы
Балтач муниципаль районы
Норма авыл җирлеге
башкарма комитетының
2022 елның 15 июлендәге
6 нчы номерлы карарына
КУШЫМТА

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге бюджет керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибе һәм вакытлары

Әлеге Тәртип, 2021 елның 16 сентябрендәге № 1569 номерлы «Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнарына (дәүләт органнарына), территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары белән идарә итү органнарына, җирле үзидарә органнарына, җирле администрация органнарына бюджет керемнәренең баш администраторы вәкаләтләрен беркетүгә һәм Россия Федерациясе субъекты бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслауга, территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты, җирле бюджетка карата гомуми таләпләрне раслау турында»гы Россия Федерациясе Хөкүмәте карары, 2021 елның 30 декабрендәге 1345 номерлы «Татарстан Республикасы бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә үзгәрешләр кертү тәртибен һәм вакытларын раслау турында»гы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән расланган, Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органнарына (дәүләт органнарына), территориаль мәҗбүри медицина иминияте фондлары белән идарә итү органнарына, җирле үзидарә органнарына, җирле администрация органнарына бюджет керемнәренең баш администраторы вәкаләтләрен беркетүгә һәм Россия Федерациясе субъекты бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслауга, территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты, җирле бюджетка карата гомуми таләпләрнең 10 пункты нигезендә эшләнеп, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге бюджеты керемнәренең баш администраторлары исемлегенә (алга таба – исемлек, баш администратор) үзгәрешләр кертү механизмын һәм срокларын билгели.

Баш администраторларның составы яки функцияләре үзгәргән очракта, шулай ук, Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге бюджетының керем кодлары классификациясе һәм бирү принциплары үзгәргәндә, шулай ук, Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы бюджеты керемнәрен классификацияләү кодларының баш администраторларына беркетелгән составы үзгәргәндә, исемлеккә үзгәрешләр, Балтач муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы боерыгы нигезендә, Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге башкарма комитетының 2021 елның 7 декабрендәге 15 номерлы “Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Норма авыл җирлеге бюджет керемнәренең баш администраторлары исемлеген раслау турында”гы карарына үзгәрешләр кертмичә кертелә.

Исемлеккә үзгәрешләр федераль һәм төбәк законнарына бюджет керемнәрен классификацияләү кодларының баш администраторларына беркетелгән составына үзгәрешләр кертү өлешендә кертелә.